**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Балтач авылы № **53** " **13** апрель " **2022** ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" **2003** елның **06** октябрендәге **131-**ФЗ номерлы Федераль законның **15** статьясындагы **4** өлеше, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының **2015** елның **01** июненнән **121** номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының **2021** елның **14** декабрендәге **108-12** нче номерлы «Азнакай муниципаль районы җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләренә тапшыру турында» карары нигезендә

Балтач авыл җирлеге Советы карар итте:

**1.** Татарстан Республикасы Азнакай район Советының башкарма комитетларына Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

торак мөнәсәбәтләре:

- Татарстан Республикасы муниципаль районының махсуслаштырылган торак фонды составыннан торак урыннарны кертү һәм төшереп калдыру;
- социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү;
- муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү;
- муниципаль торак фондында гражданнарга хезмәт урыны наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү;
- элек хосусыйлаштырылган торак урыннарын муниципаль милеккә кабул итү.

**2.** Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең түбәндәге башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

**-** Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты белән әлеге карарның **1** пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне кабул итү турында килешү төзергә;

**-** Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатыннан бюджет законнары нигезендә **2022** һәм **2023-2024** еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында проектын эшләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

**3.** Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: **http://pravo.tatarstan.ru** һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: **http//aznakayevo.tatarstan.ru.**

**4.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов